# Сөмбеләнең тарихы

**Нәрсә аңлата соң "Сөмбелә"? Сөмбелә ул 23 нче сентябрьгә туры килгән көн-төн тигезлеге, ягъни көн белән төннең вакыты бер озынлыкта булган көн. Шулай ук татарларда "Сөмбелә" дип "созвездие Девы" да йөртелә. Шулай килеп чыга - Сөмбелә – ул кыз, ә безнең очракта башына көзен җыела торган ашлык башакларыннан һәм башка продуктлардан торган венок кигән кыз образы килеп баса.**

**Сөмбелә ул шундый бәйрәм**
**Җәйне көздән белдерә.**
**Иген - ашлык уңса гына**
**Шатландыра – көлдерә.**





# Бәйрәм барышы

*Көзге муллык – туклык чорына туры килгәнгә күрә дә, халык “Сөмбелә” бәйрәмен аеруча көр күңел белән үткәрә торган булган. Һәр өйдә бу көнгә яңа уңыштан төрле камыр ашлары әзерләнгән, йола ризыгы һәм муллык билгесе булган бавырсак пешерелгән. “Сөмбелә” бәйрәме өйләрдән урамнарга чыккан.Авыл халкы бер матур кызны Сөмбелә итеп киендереп һәм аны уртага алып, мәйданда уен – тамаша оештырган: биегән, җырлаган, күңел ачкан. Уенда катнашучы кызлар тәкыя үреп, Сөмбеләнең башына кидерткәннәр.*

# Балалар бакчасында Сөмбелә бәйрәме

**Сөмбелә бәйрәмен менә берничә ел инде балалар бакчасында бик күңелле итеп үткәрәбез. Бәйрәмгә балалар янына Сөмбелә, яшелчәләр, уңыш бабай, болыт кунакка килә. Алар балалар белән бергәләп бәйрәм итәләр, күңел ачалар.**





# Сөмбелә бәйрәмнәре ничек уза?







# Кул эшләре күргәзмәсе







# Сөмбелә мәкальләре

Сөмбелә туса, су суыныр.

Сөмбеләдә өелеп килер.

Сөмбеләдә урып ал, арышыңны чәчеп кал.



# ***Милли бәйрәмнәр - тәрбия чыганагы.***

*Мөселман бәйрәмнәре кешедә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлылык, игелеклелек кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбиялиләр.*

***Милли бәйрәмнәребезне саклап калыйк!***

